## **Титова Гөлнур апа сөйләгәннәрдән**(1952елда туган)

Пионер оешмасына керүем 1961 елда булды. Пионер эшендә шефлык юнәлешенә зур игътибар бирелә иде. Әби-бабайларның өйләрен җыештырып, утын кертеп, чишмәдән су алып кайтып, кар көрәп аларга ярдәм итә идек. Эшләр беткәч, шунда ук бергәләп җырлап-биеп кечкенә генә "концерт " та куеп кайта идек. Бәйрәмнәрдә котлау открыткалары эшләп тапшырдык. Мондый эшләр балаларны мәрхәмәтле булырга, хезмәт сөяргә өйрәткәндер дип саныйм мин. Буш вакытны файдалы итеп үткәрергә дә булышкандыр. Безне ул елларда вожатый туплады. "4"һәм "5" билгеләренә генә укучыларны , актив булганнарны җәй көне пионер лагерена , слетка алып баралар иде**.**

**Урманасты Шынталысы**